| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 11.11.2020 г. Казань № 201-58/кс-2020

«Су белән тәэмин итү һәм канализацияләү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм су агызуга 2021 елга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Су белән тәэмин итү һәм канализацияләү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Су белән тәэмин итү һәм канализацияләү үзәге» ҖЧҖ) өчен, шушы карар кушымтасы нигезендә календарь буенча бүлеп, эчә торган суга һәм су агызуга тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Су белән тәэмин итү һәм канализацияләү үзәге» ҖЧҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.11.2020 № 201-58/кс-2020
карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Су белән тәэмин итү һәм канализацияләү үзәге» ҖЧЖ өчен эчә торган суга һәм су агызуга 2021 ел өчен календарь буенча бүленгән тарифлар

| № т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр |
| | Лаеш муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Су белән тәэмин итү һәм канализацияләү үзәге» ҖЧҖ* | | | | |
| 1.1 | Комлы Кавал һәм Орловка авыл җирлекләре кулланучылары | 32,31 | 32,31 | 40,69 | 40,69 |
| 1.2 | Габишево авыл җирлеге кулланучылары | 25,75 | 26,62 | 40,93 | 40,93 |
| 1.3 | Нармонка авыл җирлеге кулланучылары | 34,69 | 34,69 | 39,37 | 40,93 |
| 1.4 | Столбище авыл җирлеге кулланучылар | 34,69 | 34,69 | 40,69 | 40,69 |
| 1.5 | Атабай, Олы Кабан, Кирба, Макаровка, Никольский, Рождественский, Татар Саралово авыл җирлекләре кулланучылары | 34,69 | 34,69 | | |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге